Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна торак пунктында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**27.11.2023** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы 45-ФЗ Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна торак пунктында үткән үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Халык җыены карар итте:

1. Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр гражданга 2024 нче елда үзара салымны 1200 сум күләмендә кертергә. I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләр, 80 яшьтән өлкән гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм Россия Федерациясе Кораллы көчләренә 2023 елдан контрактлар төзегән гражданнарга 90% ташлама каралган.
2. Җыелган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
   - Түбән Сосна авылында урам- юл челтәрен норма таләпләренә туры китерү,
   - Түбән Сосна авылында агач кисү,
   - Түбән Сосна авылында сабан туе территориясен төзекләндерү,
   - Түбән Сосна авылында чишмә территориясен төзекләндерү,
   - Түбән Сосна авылындагы зиратларга коймалар сатып алу һәм урнаштыру,
   - Түбән Сосна авылындагы зират территориясендә инвентарьны саклау өчен бина төзү.
3. Халык җыены нәтиҗәләрен Сосна авыл җирлегенең мәглүмати стендларында урнаштырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Сосна авыл җирлеге башлыгы Ф.С.Габдрахманов